ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын мониторинглау нәтиҗәләре хакында

«Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын мониторинглау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе Р.Г. Хөсәенов мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе Р.Г. Хөсәенов мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән бергә «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына аның нигезләмәләрен актуальләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү зарурлыгы турындагы мәсьәләне карарга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына икътисад тармакларында мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат технологияләрен гамәлгә кертү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген җайга салуны дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программаларын гамәлгә ашыруны, электрон дәүләт сервисларын үстерүне, халыкка электрон дәүләт хезмәтләре күрсәтүне дәвам итәргә.

4.2. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, үстерү һәм аларның эшен тәэмин итү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актларга анализ ясарга, өстәмә хокукый җайга салу кирәклеге ачыкланганда, тиешле норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итәргә.

4.3. Системалы рәвештә Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын һәм цифрлы сервисларын исәпкә алуны һәм аларның торышын бәяләүне уздырырга, аларның эшчәнлегенә үз вакытында төзәтмәләр кертергә.

4.4. Мәгариф, медицина оешмаларында һәм башка оешмаларда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең өзлексез эшләвен тәэмин итүнең өстәмә чараларын эшләргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән бергә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларда, аларның цифрлы грамоталылыгы дәрәҗәсен арттыру белән беррәттән, мәгълүматны анализлау һәм системалаштыру күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итә торган чаралар һәм инструментлар комплексын эшләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 18 декабре
№ 25-VII ДСП